РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» март 2020 ел г. Альметьевск № 340

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен, муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча бирү нормасы буенча торак урыннар сатып алуның базар бәясенең түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен - 1 749 792 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2 227 008 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2 863 296 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 817 728 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4 772 160 сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5 726 592 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 681 024 сум;
1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 635 456 сум.

1.2. Исәп-хисап нигезендә гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен тәшкил итә (1 нче кушымта):

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданга – 17 083 сум;
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 10 871 сум;
1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен - 9 318 сум.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,

Зак. № 305-2000

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«11» март 2020ел №340
карары белән расланган
1 нче кушымта

## Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС/ (1- ((1+ПС) - КП)) / (0,3хРС), монда

ПД – гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күрсәткече;

СЖ – социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ монда:

НП – гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС – гаилә әгъзалары саны,

РЦ – Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

ПС – Бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (еллык 9,0% /12 ай =0,75%);

КП – Кредит дәвамында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны;

РС – гаилә әгъзалары саны;

0,7 – кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 – кредит буенча түләүнең гаилә айлык кереме белән нисбәте.

Торак урыны мәйданының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2020 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2019 елның 13 декабрендәге 827/пр номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 53 мең 24 сум күләмендә билгеләнгән.

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күләмен исәпләү

Табл. №1

| НП – торак урыны нормасы, (кв.м) | СЖ - торак урыны сатып алуның базар бәясе (СЖ=РСх РЦхНП), (сум) | РС – гаилә әгъзалары саны, (кеше) | РЦ - торак урынның 1 кв.м базар бәясе, (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән нисбәте | ПД-керемнең иң чик кыйммәте (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 53 024 | 9,0/12=<br>0,75 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 1 749 792 | 1 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 0,3 | 17 083 |
| 42 | 2 227 008 | 2 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 0,6 | 10 871 |
| 54 | 2 863 296 | 3 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 0,9 | 9 318 |
| 72 | 3 817 728 | 4 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 1,2 | 9 318 |
| 90 | 4 772 160 | 5 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 1,5 | 9 318 |
| 108 | 5 726 592 | 6 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 1,8 | 9 318 |
| 126 | 6 681 024 | 7 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 2,1 | 9 318 |
| 144 | 7 635 456 | 8 | 53 024 | 0,75 | 180 | 0,7 | 2,4 | 9 318 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов